**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
ЧЕРЕМШАНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**12.02.2021** **Чирмешән авылы** **№69**

**Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 20 декабрендә кабул ителгән 590 номерлы «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының торак сәясәте бүлеге тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын яңа редакциядә раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Норматив хокукый актны гамәлдәге законнарга, Татарстан Республикасы министрлыклары һәм ведомстволарының 2020 елга Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетын көтелгән үтәү йомгаклары һәм 2021 елга республика финанс, казначылык һәм салым органнарының бурычлары буенча уртак коллегиясе беркетмәсенә (04.01.2001 ел, № ПР-3) туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 20 декабрендә кабул ителгән 590 номерлы «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының торак сәясәте бүлеге тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын яңа редакциядә раслау турында» карарының 1 нче кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. 2.5 пунктына түбәндәге эчтәлекле 6 пунктча өстәргә:

«салым һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият взнослары, пенялар, штрафлар,

процентлар түләү буенча бурычның булмавы турында гаиләнең барлык әгъзаларына салым органы белешмәсе(-ләре)».

2. 3.4.1. пунктына түбәндәге эчтәлекле 8 пунктча өстәргә:

«салым һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият взнослары, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча бурычның булмавы турында гаиләнең барлык әгъзаларына салым органы белешмәсе(-ләре)».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
җитәкчесе И.Н. Шәйдуллин